ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО
ОБРАЗОВАНИЯ
ГОРОД ЛЕНИНОГОРСК

ЛЕНИНОГОРСК ШӘҺӘРЕ
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

05.08.2022 г.Лениногорск № 17

Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 9 номерлы карары белән кабул ителгән 2022 елның беренче яртыеллыгында Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан Лениногорск шәһәре урамнарыннан, шул исәптән юл өлешен, юл чатларын, җәяүлеләр өчен чыгу юлларын һәм тротуарларны да кертеп кар чистарткан һәм чыгарган өчен чыгымнарның бер өлешен каплау өчен оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә үзгәрешләр кертү турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2022 елның 5 апрелендәге «Субсидияләр, шул исәптән субсидияләр рәвешендә, юридик затларга, шәхси эшмәкәрләргә, шулай ук товар, эшләр, хезмәт күрсәтүләр җитештерүче физик затларга грантлар бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләргә үзгәрешләр кертү турында һәм күрсәтелгән субсидияләр һәм 2022 елда федераль бюджеттан Россия Федерациясе субъектлары бюджетларына субсидияләр бирү үзенчәлекләре турында» 590 номерлы карары нигезендә, Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитетының 2022 елның 1 апрелендәге 9 номерлы карары белән кабул ителгән 2022 елның беренче яртыеллыгында Лениногорск шәһәре муниципаль берәмлеге Башкарма комитеты бюджетыннан Лениногорск шәһәре урамнарыннан, шул исәптән юл өлешен, юл чатларын, җәяүлеләр өчен чыгу юлларын һәм тротуарларны да кертеп кар чистарткан һәм чыгарган өчен чыгымнарның бер өлешен каплау өчен оешмаларга субсидияләр бирү тәртибе турындагы нигезләмәгә түбәндәге үзгәрешләр кертергә:

2.5 пунктының «а» пунктчасының 3 абзацында «максатлары» сүзен «нәтиҗәләре сүзенә алмаштырырга»;

4.2 пунктның «а» пунктчасын түбәндәге редакциядә бәян итәргә:

«а) Лениногорск муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан, «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы» МКУ субсидия алучы тарафыннан субсидияләр бирү тәртибенең һәм шартларының үтәлешенә, шул исәптән субсидия бирү нәтиҗәләренә ирешү өлеше буенча мәҗбүри тикшерү үткәрү, шулай ук «Татарстан Республикасы Лениногорск муниципаль районы» муниципаль берәмлегенең Контроль-хисап палатасы» МКУнең Россия Федерациясе Бюджет кодексының 268_1 һәм 269_2 статьялары нигезендә тикшерүе турында»;

«б» пунктчасының беренче абзацында «, максатлары» сүзен төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында» http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча бастырып чыгарырга һәм Лениногорск муниципаль районының рәсми сайтында урнаштырырга.

3.Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз җаваплыгымда калдырам.

Җитәкче Р.Р. Сытдиков

Л.М.Галимова
5-44-72